**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет муниципального образования «поселок городского типа Актюбинский» Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакаевский муниципальный район,
423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» гыйнвар 2021 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлеге территориясендә агып җыела торган суларны агызу (канализация) үзәкләштерелгән системасына агып җыелган суларны агызуны хәл итүче абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын раслау турында

2003 елныц 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 маендагы 728 номерлы "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үзгәрешләрен һәм үз көчләрен югалтуын тану турында агып төшүче суларның составын һәм үзлекләрен тикшереп торуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау хакында" карарлары нигезендә,әйләнә-тирәлеккә пычраткыч матдәләрнең тискәре йогынтысын, су объектларының пычрануын кисәтү максатында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлеге территориясендә агып җыела торган суларны агызу (канализация) үзәкләштерелгән системасына агып җыелган суларны агызуны хәл итүче абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын, әлеге карарга кушымта нигезендә, расларга.

2. Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок»

муниципаль берәмлегенең үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу (канализация) системасына агып җыела торган суларны агызу (җибәрү) белән шөгыльләнүче барлык абонентларга юынтык суларның составы нормативларын үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И. Мөхәмәтҗанов

Азнакай муниципаль районы "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлеге башкарма комитеты карарына кушымта «20» гыйнвар 2021 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлегенең үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасына (канализация) агынты суларны агызуны хәл итүче абонентлар өчен агынты сулар составы нормативлары

| № п/п | Матдә (күрсәткеч) атамасы | Максималь рөхсәт ителгән күрсәткеч һәм (яки) концентрация (җыелма эчтәлеге һәм табигый су пробасы буенча), мг/дм3 (мг/л) |
|---|---|---|
| 1. | Аммоний-ион | 25 |
| 2. | АПАВ | 0,2 |
| 3. | БПК5 | 300 |
| 4. | Үлчәнгән матдәләр | 300 |
| 5. | Тимер | 0,13 |
| 6. | Марганец | 0,3 |
| 7. | Нефть продуктлары | 0,1 |
| 8. | ХПК | 500 |
| 9. | Алтывалентлы хром | 0,02 |
| 10. | Сульфатлар | 100 |
| 11. | Фосфатлар фосфоры | 12 |
| 12. | Хлорид | 300 |
| 13. | Оча торган феноллар | 0,007 |